Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының илле дүртенче утырышы

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

2019 елның 23 сентябре, № 138

**Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча
дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында**

Россия Федерациясенең нотариат турында 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы закон Нигезләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1, 20 статьялары нигезендә Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә:

1) күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслауга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрүгә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең чынлыгын раслауга;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләүгә;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклауга;

6) гражданның исән булу фактын таныклауга;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз кулы белән имзасының, үз кулы белән имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген раслауга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклоуга;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклауга;

10) документлар тапшыру вакытын таныклауга;

11) документның кәгазьдә урнаштырылган документның бердәйлеген раслауга;

12) документның кәгазьдә электрон документка тиңлелеген таныклауга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының 2007елның 23 декабрендә кабул ителгән 30 номерлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru, Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) әлеге карарны игълан итәргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов